وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№14 (209). 25 октябрь 2013/20-зөлхиҗҗә-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

## "ИСЛАМ – РОССИЯ ТАРИХЫНЫҢ АЕРЫЛГЫСЫЗ ӨЛЕШЕ"



**Шушы көннәрдә Уфада Россия Үзәк Диния нәзарәте оешуга 225 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар узды. Бәйрәм чараларында Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин да катнашты.**

Россия Президентының Россия мөселманнары Диния нәзарәтләре рәисләре белән очрашуы вакытында дәүләт, мөселман дини оешмалары һәм ислам дини тәгълиматы мәктәпләренең үзара мөнәсәбәтләре турындагы актуаль мәсьәләләр каралды. Россия Президенты сүзләренә караганда, бүгенге көн каршылыкларына бирешмәс өчен, беренче чиратта, үзебезнең мөселман руханыйларының һәм Россиядәге ислам дине тәгълиматы мәктәпләренең дәрәҗәсен күтәрергә кирәк.

"Иң мөһим мәсьәләләрнең берсе - үзебезнең ислам дине тәгълиматы мәктәбен торгызу. Бу Россия дини пространствосының бәйсезлеген булдырачак, чөнки башка илләрдәге мөселман галимнәре дә аны таныячак... Бу мәктәп Россиядәге һәм, гомумән, дөньядагы иң актуаль сорауларга җавап бирергә тиеш; барысы да аңлаешлы һәм мөселманнар өчен ышаныч казанган булырга тиеш. Әнә шуларны башкарсак, бу сезгә начар һәм яхшы гамәлләргә үз бәягезне бирергә булышачак, дип уйлыйм", - диде Владимир Путин.

Президент Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә нигез салынуга 225 ел тулу уңаеннан оештырылган тантанада да катнашты.

"Ислам - Россия мәдәниятенең көчле бер элементы, Россия тарихының аерылгысыз өлеше. Без ислам динен тотучылар арасыннан булган күп кенә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләрен, мәдәният һәм сәнгать вәкилләрен, танылган хәрбиләрне беләбез", - диде В.Путин үз чыгышында. Президент Бөек Ватан сугышы елларында Уфада узган мөселманнар корылтаенда Габдрахман Рәсүлевнең Ватанны яклауның изге бурыч булуы турында сөйләвен искә төшерде: "Бу безнең уртак тарихыбыз, сугыш кырларында бергә сугышкан, соңрак бергәләшеп илне торгызган, беркайчан да кешеләрне милләт яки дин буенча бүлмәгән ата-бабаларыбыз истәлеген сакларга тиешбез", - дип ассызыклады В.Путин.

Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте оешуга 225 ел тулуга багышланган тантаналы чараларда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты. Камил хәзрәт төрле илләрдән, төрле төбәкләрдән килгән дин әһелләре белән аралашты. Дин әһелләре үзара мөселман өммәтенә кагылышлы вакыйгалар, дини эшчәнлек алып бару хакында фикер алышты.

## ХАҖИЛАР КАЙТА

***23 нче октябрьдә "Казан" халыкара аэропортына Согуд Гарәбстаныннан турыдан-туры авиарейс белән хаҗиларның беренче төркеме - барлыгы 218 кеше кайтты. Очкыч баскычыннан яңа гына төшкән хаҗилар дулкынлануларын, сөенеч-шатлыкларын каршы алучылардан да, камера, диктофоннар белән "коралланган" журналистлардан да яшереп тормады. Бу халәт аңлашыла да: үз гомерендә бер генә тапкыр булса да хаҗ сәфәрендә булу, өммәтебез өчен изге булган урыннарда гыйбадәт кылу, сөекле Пәйгамбәребез (с. г. в.) ислам динен тараткан урыннарны күрү турында кайсы мөселман гына хыялланмый икән!***



Билгеле булганча, быел "ДУМ РТ Хадж" программасы буенча Татарстаннан 1200 кеше хаҗ кылды. Алар арасында Татарстан мөфтиенең дәгъвәт буенча урынбасары Нияз хәзрәт САБИРОВ та бар иде. Казанга кайткач, хаҗ сәфәреннән алган тәэсирләре белән уртаклашуын сорап, без хәзрәтнең үзенә мөрәҗәгать иттек:

- Хаҗга минем өченче тапкыр баруым. Бу юлы хаҗ сәфәребез бик яхшы оештырылган иде, хаҗиларның барысына да бик ошады. Хаҗ - олы гыйбадәт тә, Кыямәт көненә бер мисал да. Күз алдына китерегез әле: анда дөньяның төрле почмакларыннан егерме миллионга якын мөселман җыела. Бае да, ярлысы да, яше дә, карты да - Аллаһы Тәгалә каршында барысы да бертигез, барысы да бертөсле ихрамнан. Бу, без барыбыз да Аллаһның коллары, барыбыз да бер Аның рәхмәтенә мохтаҗбыз, дигәнгә ишарә инде. Пәйгамбәребез (с. г. в.): "Үлгәнчегә кадәр үлегез", - дигән. Монда һәркем үлемне искә төшереп, Аллаһка чын күңелдән ялвара. Күңелнең иң нечкәргән мизгеле Гарәфә үзәнлегендә өйлә намазыннан алып кояш баеганчыга кадәр аягүрә гыйбадәт кылганда булгандыр. Хис-кичерешләрне сүзләр белән генә әйтеп бетерә алмыйм. Үзебез өчен генә түгел, гаиләләребез, туганнарыбыз өчен дә дога кылдык без анда. Аллаһы Тәгаләдән илкөннәребезгә тынычлык-бәрәкәт бир, афәтләрдән сакла, ислам дине тагы да ныграк таралсын, дип сорадык. Әл-Хәрәм мәчетендә укыган намазны бер җирдә укыганы белән дә чагыштырып булмый. Чиксез рухый ләззәт... Без Нур тавына да мендек. Андагы Хира мәгарәсендә Пәйгамбәребезгә (с. г. в.) беренче аятьләр иңгән. Тау бик биек дип тормадылар, 75 яшьлек әбиләр дә менделәр анда. "Аякларым авыртa, шайтанга таш атарга бара алмам инде", - дип борчылучылар да өч-дүрт чакрым араны һич уфтанмыйча әйләнеп кайттылар. Аллаһы Тәгалә анда җиңеллеген дә биреп тора.

***Мәрьямбану ХАФИЗ***

## ЯҢАЛЫКЛАР

### КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИН МӨХТӘСИБӘТЛӘРДӘ БУЛДЫ

**23 нче октябрьдә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Уфадан Казанга кайтышлый мөхтәсибәтләр эшчәнлеге белән танышу максатыннан берничә район мәчетләренә тукталды.** Мөфти Актаныш, Чаллы, Мамадыш мөхтәсибәтләрендә булды. Районнардагы дин әһелләре белән очрашулар вакытында сүз мөселман инфраструктурасын үстерү, яшь белгечләрне дини эшчәнлек алып баруга җәлеп итү, рухый мирасны торгызу, дини эшчәнлек алып бару һ. б. турында барды.

### "ХОЗУР"ДА ЯҢА КИТАПЛАР ЧЫКТЫ

**"Хозур" нәшрият йорты яңа китаплар бастырды.** Бу юлы нәшрият йорты укучыларга "Смысл шафаата" һәм "Слышат ли умершие?" брошюраларын тәкъдим итә. Әлеге хезмәтләрнең авторы - хәнәфи мәзһәбенең бүгенге заман төрек дин галиме Сәет Али Кушавчи. Ул "Хозур" нәшриятына үзенең хезмәтләрен бастырырга рөхсәт бирде. Әлеге китаплар йөгерек әдәби тел белән язылган һәм анда исламга кагылышлы күп кенә сорауларга җавап табарга була. Китаплар бишәр мең данә белән нәшер ителде. Ул дин әһелләренә, студентларга, шәкертләргә һәм шулай ук киң катлам укучыларга атап чыгарылды.

### КИЛӘЧӘККӘ БЕЛЕМ БЕЛӘН...

**Казанның Мәрҗани мәчете карамагында эшләп килүче "Балалар" үзәгендә 3-4, 5-7 яшьлек балалар өчен ярты көн эшли торган төркемнәр ачыла.** Төркемнәр иртәнге сәгать тугыздан алып көндезге сәгать өчкә кадәр эшли. Әлеге төркемнәрдә дини белемнәр бирелә, тәрбиячеләре белән уеннар алып барыла. Малайлар өчен - дзюдо, кызлар өчен "Остабикә" түгәрәкләре эшләячәк.

"Үзәкне оештыру идеясе ничек туды?" - дигән сорауга төркемне оештыручыларның берсе Алсу Хафизова болай дип җавап бирде: "Минем үземнең "Киләчәккә белем белән" дигән проектым бар иде. Шушы идея белән Мансур хәзрәт Җәләлетдиновка килдем. "Үземнең дә шундый хыялым бар иде", - дип ул минем тәкъдимемне күтәреп алды. Аның финанс ярдәме белән, әлеге идеяне тормышка ашырабыз", дип хәбәр итә "Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы.

### КЫЗЫЛТАУДА МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ

**Апас районы Кызылтау авылында мәчет ачылды.** Шушы авылда туып үскән, хәзерге вакытта Казанда һәм Чистайда яшәүче эшмәкәр егетләр - Шәүкәт Нигъмәтуллин, Насыйх Мингалиев, Камил Нигъмәтуллиннар, читтә яшәүче авылдашлар һәм авыл халкы тырышлыгы белән салынган гыйбадәт йорты, тау өстеннән авылга нур чәчеп, ямь биреп балкып тора.

Мәчет ачылышында район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Марат Ногманов, район мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев катнашты. Авыл җирлеге башлыгы Шәүкәт Гаффаров әйтүенчә, элек авылда ике мәчет булган.

- Соңгы елларда аның берсе генә эшләп килде. Дини бәйрәмнәргә читтә яшәүче авылдашларыбыз күп кайта, мәчеткә сыймаган вакытлар да булды. Халык белән җыелып сөйләштек, киңәштек тә шушындый изге эшкә тотындык. Өч ел эчендә менә шундый мәчет ачу бәхетенә дә ирештек, - диде ул.

Мирхәт хәзрәт тә Кызылтау авылы халкын иманга килергә өндәде, эчүчелек, начарлыктан арынуны теләде. Яшьләрне дә дин юлына басарга чакырды.

Килгән барлык халык өчен бик зур өстәл әзерләнгән иде. Шунда ук пылау пеште, самавырларда чәй кайнап торды, күчтәнәч бәлештән дә авыз иттеләр, дип хәбәр итә "Йолдыз" газетасы.

Камил СӘМИГУЛЛИН:

# "БЕЗГӘ КАРДӘШЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕН НЫГЫТЫРГА КИРӘК"

**"Динебез бер, кыйблабыз бер, бер тарафка карап намаз укыйбыз. Шуңа күрә безгә кардәшлек мөнәсәбәтләрен ныгытырга һәм төрле өлкәләрдә хезмәттәшлек итәргә кирәк". Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин әлеге сүзләрне Грозныйда Корбан гаете һәм "Чечня йөрәге" мәчете ачылуга биш ел тулу уңаеннан уздырылган бәйрәм тантанасында әйтте. Әлеге күркәм бәйрәмгә Төньяк Кавказ төбәкләреннән дин әһелләре җыелган иде. Татарстан мөфтие, чарага килүчеләрне сәламләп, бәйрәм белән котлады. Ул Чечня җитәкчелегенең чечен халкы традицияләрен саклауда зур тырышлык күрсәтүләрен, шулай ук Татарстан белән Чечня арасында элемтәләр кору мөһимлеген билгеләп үтте.**



Бәйрәм тантанасыннан соң Камил хәзрәт Чечня мөфтие Солтан Мирзаев белән очрашты. Солтан Мирзаев Камил хәзрәткә Чечняга килүе өчен рәхмәтен белдерде, аннары мөфтият делегациясе өчен махсус экскурсия оештырды. Ул кунакларны республиканың күркәм урыннары, мәчетләре белән таныштырды.

Чечня Республикасына эшлекле сәфәре кысаларында Камил хәзрәт Сәмигуллин Кунт Хаҗи исемендәге Россия ислам университеты студентлары белән очрашты. Университетның актлар залында Камил хәзрәт Сәмигуллин гакыйдә, фикыһ, тәсаувыф (суфыйчылык) гыйлемнәренә кагылышлы лекция укыды. Студентлар хәзрәткә лекция темасы буенча гына түгел, ә аның мөфти буларак эшчәнлегенә дә кагылышлы сораулар бирделәр, соңыннан кызыклы чыгышы һәм җаваплары өчен рәхмәт белдерделәр. Камил хәзрәт тә очрашудан алган тәэсирләреннән канәгать калуын һәм мөмкинлек чыгу белән бирегә кабат киләчәген әйтте.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Грозныйда Чечня Республикасы Президенты Рамзан Кадыйров белән дә очрашты. "Камил хәзрәт шәйх Кунт Хаҗи Кишиев исемендәге Россия ислам университеты студентларына ваһһабчылык, экстремизм куркынычы турында сөйләде. Аның белән очрашу вакытында да без шушы темага әңгәмә кордык. Әлеге кискен мәсьәлә буенча аның тирән белемле булуы һәм яшьләрне ваһһабчылык йогынтысыннан йолып калуда күп эшләве сокландыра", - дип язды Чечня Республикасы Президенты Рамзан Кадыйров үзенең Instagramдагы шәхси блогына.

Эшлекле сәфәре барышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинны аның урынбасары Илдар хәзрәт Баязитов,Россия Мөселманнары эшкуарлары ассоциациясе президенты Радик Гафуров озатып йөрде.

## БИРЮЛЁВОДАГЫ ХӘЛЛӘР ҖӘМГЫЯТЕБЕЗНЕҢ ҖИТЛЕКМӘГӘН БУЛУЫН КҮРСӘТТЕ



**Мәскәү янындагы Бирюлёвода булып узган вакыйгалар милләтара мөнәсәбәтләрне билгеләүче сәясәтне формалаштыру турында уйланырга тагын бер сәбәп булып тора.**

Россиядә милләтара мөнәсәбәтләрне төзүдә башкалар өчен үрнәк булырлык регионнар бар. Шуларның берсе - Татарстан. Әлбәттә, Татарстанда да билгеле бер кыенлыклар бар, ләкин вакыт республикабыздагы милләтара мөнәсәбәтләрне билгеләүче сәясәтнең нәтиҗәле булуын күрсәтте. Миграция, төрле милләт һәм дин кешеләре арасындагы мөнәсәбәтләрне урнаштыру мәсьәләләрен Татарстан башка регионнарга караганда нәтиҗәлерәк хәл итә.

Тәртипкә китерелмәгән миграция сәясәте һәм үзләрен "демократ", "либерал" дип атаучы кайбер массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан мигрантларга карата оештырылган истерия үзен һаман сиздереп тора. Тәртипсезлекләрнең Мәскәү мэрын сайлаулардан соң узуы гаҗәп түгел - бу проблеманы нәкъ менә мигрантлар темасында спекуляция ясарга тырышкан оппозиция күтәреп чыккан иде. Бирюлёводагы тәртипсезлекләрнең милләтчел оешмалар тарафыннан оештырылуы инде исбат ителде. Бу оешмалар өчен мигрант - Россия җәмгыятенең барлык проблемаларында гаепле дошман. Шуны да аңларга кирәк, алар өчен мигрант һәм мөселман - бертигез. Шуңа да мөселманнар өчен изге булган Корбан бәйрәме көнендә милләтчеләрнең "Корбан бәйрәменә безнең җавап" исеме астында төрле провокацияләр оештырулары очраклы хәл түгел. Килеп чыккан хәлне соңгы чигенә җиткерергә тырышалар дигән фикер туа. Бу очракта ике якны да аңларга, алар белән уртак тел табарга сәләтле арадашчы, медиатор кирәк.

Низагларны бетерүдә төп корал булып диалог тора, нәкъ менә Татарстанның горурлыгы булган мәдәниятләр диалогы - проблеманы чишүнең төп ысулы. Ләкин диалогка кадәр җитлегергә, үсеп җитәргә кирәк. Бары тик фикер камиллеге, зирәклек кенә кешеләргә берберсен ишетергә ярдәм итә. Бирюлёводагы хәл җәмгыятебезнең җитлекмәгән булуын, килеп чыккан проблемаларны чишә белмәвен күрсәтте. Кызганыч, әлегә бу өлкәдә хәрәкәт диалогка таба түгел, ә киресенчә, низагка, торган саен күбрәк кешене үзенә тартып, җәмгыятебезне һәлакәткә китерә торган низагка таба бара.

***Илдар хәзрәт БАЯЗИТОВ,***
***Татарстан мөфтие урынбасары***

*Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН:*

## "ИМАМНАР ДӨНЬЯВИ ҖӘМГЫЯТЬТӘ МӨНӘСӘБӘТЛӘРНЕ КОРА БЕЛЕРГӘ ТИЕШ"

**"Без бу курсларны бик мөһим дип саныйбыз. Эш дәверендә имамнарның проблемалары җыела, бик күп сорауларга җавап табарга кирәк. Безнең иң яхшы укытучыларыбыз сезне кызыксындырган мәсьәләләр буенча дәресләр алып барыр. Монда килгәч, барлык әһәмиятле сорауларыгызга җавап табарга тырышыгыз. Бу алга таба сезнең эшне җиңеләйтер дип уйлыйбыз. Сез бу мәсьәләләрне хәнәфи мәзһәбе, мәтуриди гакыйдәсе буенча хәл итәрсез дип өметләнәм", - дип белдерде Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин Идел буе округындагы Ислам дин әһелләренең квалификациясен күтәрү үзәген ачу вакытында. Курслар Россиянең Монополиягә каршы федераль хезмәте базасында уза.**

Әлеге үзәктәге укулар РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле, ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты, Россия ислам институты, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәнияте, үсеш һәм мәгарифкә теләктәшлек итү фонды тарафыннан оештырылды.

Беренче агымда ике атна дәвамында Татарстан районнары, Идел буе федераль округына кергән Ульяновск, Мордовия, Чуашстан Республикалары, Пермь өлкәсе имамнары - югары дини белеме булмаган утызлап имам белем алачак. Әлеге курслар шулай ук мөселман оешмалары хезмәткәрләре өчен дә каралган. Аларга Россия ислам институты, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе, Казан (Идел буе) федераль университеты укытучылары, Татарстан мөфтиятеннән остазлар, зур мәчетләр имамнары белем бирәчәк. Белем бирү ике блоктан - дини һәм дөньяви өлешләрдән тора. Беренчесендә - Коръән уку, ислам хокукы (фикыһ) һәм башка дини дисциплиналар, икенчесендә - хокук, тарих белән бәйле предметлар, дини оешмаларда финанс, уку эшләрен оештыру, террорчылык һәм экстремизмны кисәтү, массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү һ. б. Бер сүз белән әйткәндә, имамнарны дини оешма дәрәҗәсендә нәтиҗәле эшләргә, дәүләт хакимияте структуралары һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә, иң мөһиме - төрле агымнарны аера белергә, проблемалы мәсьәләләрне вакытында күрә белергә һәм үзләрен әлеге вәзгыятьтә дөрес тотарга өйрәтәчәкләр. Дәресләрдән тыш, имамнар өчен төрле очрашулар, "түгәрәк өстәл" утырышлары да уздырылачак. "Сүз дә юк, имамнар дөньяви җәмгыятьтә мөнәсәбәтләрне кора белергә тиеш", - дип саный РИИ ректоры, сәясәт фәннәре докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин.

Ел ахырына кадәр 125 имам белем күтәрү курсларында укып, аттестацияләнәчәк, аларга Россия ислам институты базасында кыска вакытлы курслар узу турында сертификат биреләчәк.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанда мондый үзәк ачылуны зур нигъмәт дип белдерде. "Монда белем эстәп, без аралаша алабыз. Республикаларыбыз төрле булса да, динебез -

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# ӨММӘТЕМ ҮСЕШЕ ӨЧЕН МИН НӘРСӘ БИРӘ АЛАМ?

**Мәдинә Кәлимуллина – ислам икътисады һәм финанслары өлкәсендә шактый билгеле белгеч. Ул РФ Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү дәүләт халыкара элемтәләр институтын тәмамлаган, халыкара икътисадый бәйләнешләр һәм тышкы икътисадый элемтәләр кафедрасында белем алган. Хәзерге вакытта Россия Мөфтиләр шурасының икътисад департаменты директоры, күп кенә проектларның җитәкчесе.**



**- Мәдинә, өммәтебезнең икътисадый яктан үсешен һәм ислам икътисадында Казанның тоткан урынын ничек бәялисез?**

- Әлегә без башлангыч чорда гына. Өммәтебезнең икътисадый үсешен бәяләүгә килгәндә, икътисадый операцияләрне ислам кануннары белән килештереп алып баручы фикердәшләр төркеме тупланды. Бу аларның тормыш кануны – эшчәнлекләре шуңа инандыра. Мондый төркемнең барлыкка килүе өммәтебез өчен казаныш, әлбәттә, әмма бу әлегә бик аз. Кызганыч ки, күп кенә кешеләр сорауны "Ислам үсеше, өммәтем үсеше өчен мин нәрсә бирә алам?" дип түгел, ә "Ислам миңа нәрсә бирә?" дип куя. Бу шулай, һәм бу бер Россиядә генә түгел. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай, алга таба да шулай дәвам итәр, мөгаен.

Үткәргән чараларның нәтиҗәләренә тукталсак, финанс-икътисадый яктан өммәтебез үсешенә битараф булмаучылар саны үсә бара. Алар белем ала, намус кушканча яшәргә тырыша, чөнки әле хәләл җитештерүчеләр арасында да этиканы; килешүләрне; хезмәткәрләр, клиентлар, партнёрлар һ. б. белән дөрес мөгамәләне саклау төп проблема булып кала. Безгә этика өстендә эшлисе бар әле.

Төбәкләр арасында ислам икътисады үсеше буенча Татарстан Россиядә, һичшиксез, лидерлар рәтендә. Беренче чиратта, бу шуннан килә – Татарстан Россиянең тарихый ислам үзәкләренең берсе; аерым шәхесләрнең тырышлыгы белән KAZANSAMMIT һ. б. проектлар эшли башлады; хәләл бизнеста, инфраструктура өлкәсендә проектлар булуын да әйтергә кирәк (монда да Татарстан башка төбәкләрдән алда бара). Хәзер Кавказ, аерым алганда, Дагстан, Чечня Республикасы, бик актив шөгыльләнә башлады. Кавказ белән чагыштырганда, Татарстанның өстенлеге аның икътисадый яктан тотрыклы төбәк булуында. Икенчедән, Татарстан Хөкүмәтенең эшчәнлеген билгеләп үтәргә кирәк. Беренче саммит башланганчы ук Рөстәм Нургали улы Миңнеханов (ул чакта Татарстан хөкүмәтен җитәкли иде) ислам финансларының һәм ислам икътисадының әһәмиятен югары дәрәҗәдә аңлады. Хәзерге вакытта Татарстанга саммитка ислам илләреннән ышаныч белән киләләр икән – бу күп нәрсә хакында сөйли.

**- Департамент оешканга өч ел тулып килә. Шул вакыт эчендә нәрсәгә ирешелде? Нинди проектлар тормышка ашырылды?**

- Кайбер проектларга нәтиҗә ясау авыррак, әгәр дә белем алу турында әйтәбез икән, күпме кеше мәгълүмат алган, күпме кеше финанслауның хәрәм саналган юлларыннан баш тарткан – хакыйкатьне бер Аллаһы Тәгалә генә белә бит. Конкрет проектларга тукталсак, ислам финансларыннан белем бирү буенча без Мәскәү халыкара бизнес мәктәбе белән бергәләп эшлибез. Эшкуар, банкир, менеджер булып өлгереп җиткән кешеләргә белем бирәбез. Департаментның иң эре проектларының берсе "Хәләл" Мәскәү халыкара күргәзмәседер, мөгаен. Аны инде бишенче тапкыр үткәрергә әзерләнәбез. Башка проектларыбыз да бар, алары әлегә әзерлек этабында.

***Чыганак: www.islam-today.ru.***

# ИРЕКСЕЗДӘН АСТРОНОМ

**Бәләкәй чакта кулыма бер китап эләккән иде. Шуннан хәтергә бик куркыныч хәбәр уелып калган: бер намазын вакытыннан кичектергән кеше тәмугта 360 мең ел янар, ди. Бу хәбәрнең дөресме, түгелме икәнен белмим, бәлки бу сүз уйдырма булып, Пәйгамбәребез (с. г. в.) сүзе түгелдер, ләкин шуннан бирле намаз вакытларына игътибарлы булып киттем. Чөнки Аллаһы Тәгалә Үзе Коръәндә әйтә: "Дөреслектә, намаз мөэминнәргә билгеле вакытта кылырга дип йөкләнде" ("Ниса", 103).**

Аллаһның тәкъдире белән бабаларыбыз шушы ике Идел кушылган төбәккә килеп төпләнгән. Ислам динен кабул иткәнче күчкәннәр шул, югыйсә озын уразалы, соң ястүле һәм иртә таңлы төбәкне сайламаган да булырлар иде. Ләкин язмыштан узмыш юк, ди халык, һәм ул хаклы да. Намаз вакытлары белән килеп чыккан бер вакыйга турында әле ерак Багдадтан килгән Ибне Фазлан язып калдыра. Шәһре Болгар мәзиненең, иртәнге намазны йоклап калырмын дип куркып, җәй буе йокыга ятмыйча, таң атуны көтеп утыруы турында да мәгълүмат бар аның язмасында. Ул чорда бабаларыбызның исламга килүләренә күп вакыт узмаса да, күрәсең, алар бик тәкъва булган.

Безгә якынрак яшәгән бабабыз Галимҗан хәзрәт Баруди да намаз вакытларын ригайә кылу (игътибарлы булу) турында үзенең журналында болай дип яза: *"Намаз торгызу - вакытларын кайгыртуны да үз эченә аладыр. Вакыт кебек бөек шарты вә хикмәте кайгыртылмаса, намаз торгызылган намаз булмый, егылган намаз булыр.*

*Аллаһның рөхсәте белән Җәбраил галәйһиссәлам Рәсүлүллаһка (салләллаһу галәйһи вәссәлам) биш намазның иң шәрәфәтле вә күп саваплы вә чын тиешле вакытларын билдергән вә бәрабәр укып күрсәткән, үзең вә өммәтең өчен намаз вакытлары ошбу, дип кисәткән.*

*Бәс, һәр мөэмин үзрә Аллаһның ризалыгын эстәүче вә Пәйгамбәргә ышанучы вә аның юлы үзрә китүче вә аның тәгълимен йөкләүче булган өчен тиештер ки намазны Аллаһ теләгән вә фәрештә өйрәткән вә Пәйгамбәр боерган вә үтәгән вакытларда үтәсен вә шул вакытлар шәрәфәтендә намаз белән күп хәер вә савап көтсен.*

*Хуҗасы тарафыннан ачык боерылган вә үтәүгә ашыктырылган хезмәтне кичектерү - хезмәтченең олуг гаебе вә бик оялырлык гөнаһыдыр. Әмма вакыты килү белән кичектерми тиешле вә күркәм рәвештә ул хезмәтне үтәү мактаулы вә хуҗаның ризалыгына вә яхшы бүләгенә сылтау була вә хезмәтченең үзенең дә күңеле рәхәт вә тыныч булуына сәбәп була.*

*Менә шул үлчәү белән генә караганда да намазның вакытын саклау тиешле икәнен вә ялкауланып кичектерү вә игътибарсызланып оныту яки калдыру вә байтак куркынычлы вә алдагы көндә олуг җәзага дучар булырга сәбәп булуы бик ихтималдыр. Намазны вакытында үтәүнең фазыйләтендә төрле хәдис шәрифләр килгән вә күп вәгъдәләр булган вә һәм кичектерүнең яманлыгында күп куркынычлы хәбәрләр сабит булган вә олуг гөнаһ икәне аңлатылган. Мин бу урында бу ике эшнең дәрәҗәсен тугры акыл буенча гына аңлатасым килде вә һәм ошбуңа кечкенә генә кувәтем вә кыска гына сүзем берлә хакны аңлыйсы килгән кеше аңлардыр дип өметләнәм".*

Шулай булса да, географик урнашуыбыз намаз вакытларына төрлечә карарга мәҗбүр итә. Казан татарларының шундый бер чоры булган - ястү намазын бөтенләй укымаганнар. Майның 19 нчы числосыннан алып 28 нче июльгә кадәр ястүне ташлаганнар. Шулай дәвам итәр иде, ярый әле Курсави һәм Мәрҗани хәзрәтләре тырышлыгы белән бу гадәт юкка чыга һәм мөселманнар биш вакыт намазларын калдырмый башлый.

Совет чорында намаз уку бик тә сирәгәя, юк дәрәҗәсендә кала. Намаз вакытларын билгеләүче календарьлар чыгарып тарату мөмкинчелеге булмаганга, мөфтият, кояш чыгуга кадәр сәгать ярымны алып, баегач сәгать ярымны кушып, намаз вакытларын билгели. Үзгәртеп кору елларында янәдән мәчетләребез ачылып, намаз укучылар күбәя. Намаз вакытларын билгеләүче календарьлар чыга башлый. Менә шул вакытта да кояш батуга сәгать ярым кушып - ястү намазын, кояш чыгудан сәгать ярымны алып иртәнге намаз вакытын билгеләү практикасы кала бирә. Нәрсәгә таянганнар, ничек санаганнар? Югыйсә ул чорда чыккан мәшһүр "Гыйбадәте исламия" китабында да сәгать ярым кушыгыз я алыгыз димәгән ич. "Һәр намазны вакытында уку - фарыздыр. Вакыты кермәс борын укылган намаз - фарыз намазга хисап кылынмас. Ястү вакыты - шәфәкъ кызыллыгы беткәннән башлап, таң яктылыгы җәелгәнчедер", - дип язылган анда.

Җәй көннәрендә ястү намазына мәчеткә намазга барганда күбебез игътибар итәдер: кояш баткан туры кып-кызыл, әле шәфәкъ сүрелмәгән була, шул вакыт ястү намазына мәзин азан әйтә башлый. Ә вакыты кергәнче укылган намаз кабул булмый, ди бит Максуди хәзрәтләре! Традицион исламмы, башкасымы - намазны вакытында уку кирәк. Традицион ислам дигәннән, революциягә кадәр чыккан календарьларда хәтта гыйнвар аенда да ахшам белән ястү арасы ике сәгатьтән дә ким түгел, кайчак ун минутка артык та. Менә, мәсәлән, 1913 нче елның 14 нче гыйнвары (яңа стиль) өчен намаз вакытлары:

*"Заман" календаре:*

**Таң беленер - 6.12;**
**кояш чыгар - 8.23;**
**төш вакыты - 12.08;**
**икенде вакыты - 13.20;**
**кояш батар - 15.55;**
**ясигъ вакыты - 17.55.**

1895 нче елгы календарьның декабрь ае өчен булган намаз вакытларын да карыйк:

*13 нче декабрь:*

**Таң атар - 5.59;**
**кояш чыгар - 8.23;**
**кояш батар - 15.25;**
**шәфәкъ батар - 17.47;**
**өйлә вакыты керер - 11.54;**
**икенде вакыты керер, бер күләгә - 13.00; ике күләгә - 13.20.**

Таң ату да, күргәнегезчә, кояш чыгудан ике сәгатьтән артык алдарак булган. Бу иң кыска көннәрдә, кыш уртасында. Ә көн җәйгә авышкач, ул ара тагы да арта, төн кыскара, кыскара да, май ахырларында ястү намазы вакыты керми башлый. 1903 нче елгы бер календарьда "11 нче августта 19.16 сәгатьтә кояш бата, 22.20 сәгатьтә ястү керә" дип язылган, кайберләрендә ике сәгать кенә алынган. Бу җәй буе дәвам итә: июль ахырларына кадәр офыктан кызыллык китми һәм август башында гына төннәр башлана.

Ә бит кояш чыгу һәм бату мәсьәләсе намаз белән генә түгел, ураза белән дә турыдан-туры бәйләнгән. Әхмәдһади хәзрәтләре яза: "Рамазан аенда һәркөн рузә булу, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан баш-

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# ЯЛГЫЗ КАРТЛЫК

**Корбан бәйрәменең икенче көнендә Серов урамындагы мәчетебезгә шактый таушалган бер абзый килеп керде. Таушалган дигәч тә, салып йөри торган кеше икән, дип уйлый күрмәгез тагын.**

Юк, һич тә юк. Ул абзыйга күптән түгел инсульт булган. Сул кулы параличланган, аякларына да шактый гына зарар килгән - таякка таянып, аксаклап кына йөри. Безгә корбан ите алып килгән. "Гафу итегез, мәчетегезнең ачылышына килә алмадым. Ул вакытта минем йөрәк сыкрап торды. Менә хәзер хәлем бераз ярыйсылангач, керергә җай чыкты", - дип башлады ул сүзен һәм үз тормышын сөйләп китте.

Хәкимулла абзый хатыны Әлфия белән 1975 нче елда аерылышкан. Сәбәбе шул: хәләл җефете салырга яраткан, хәтта башка ирләр белән дә типтерә башлаган. Ике кыз баланы Хәкимулла абзыйның берүзенә тәрбияләп, аякка бастырырга туры килгән. Әлбәттә, авыр чаклар бик күп була аның тормышында. Сыкранмый, зарланмый гына тормышын берүзе сөйри ялгыз ир-ат. Хәзерге көндә шуның татлы җимешләрен татый.

- Йөрәк өянәгенең беренчесен моннан биш ел элек кичердем. Менә шул вакытлардан бирле исән-сау булып яшәвемә кызларыма бурычлымын. Аллаһның рәхмәте булсын аларга. Инде авырмый да тормам, яшем шактый - быел 77 тулды, - диде заманында табиб булып эшләгән Хәкимулла абзый.

Картлык үз эшен башкара шул, колаклары да шактый ныгыган, кайбер сорауларымны язмача да бирергә туры килде үзенә. Минем: "Башка өйләнмәдегезме?" - дигән соравыма, ул: "Әйе, кызларым үсеп җиткәч, тагын бер тапкыр бәхетемне сынап караган идем, икенче хатыным яман шештән вафат булды. Шуннан бирле ялгызым гына яшим", - дип җавап бирде. Аның сөйләвенә караганда, Әлфияне үзе 38 ел буена бер тапкыр күрмәсә дә, кызлары аның язмышы белән гел кызыксынып торган. Хатын соңгы вакытларда әти-әнисе фатирында япа-ялгыз яшәп, быел җәй үлеп киткән, хәтта авызына су салучы да булмаган бичараның.

Әлфия дә кызганыч, 62 яшендә тол калып, берьялгызы гомер кичерүче Хәкимулла абзый да бик җәл. Гомер буе берберебезгә тугры булып, кадерләребезне белеп яшәрбез, дип вәгъдәләр бирешеп кавышкан пар булгандыр алар да. Әмма язмыштан узмыш юк шул. "Болын хәтле өч бүлмәле фатирда берүзем яшәп ятам, - дип дәвам итте сүзен Хәкимулла абзый, минем уйларымны сизгәндәй. - Элек анда бер ректор яшәгән булган. Рәхәтен күр бу фатирның, дип әйтеп калдырды. Рәхәтен бүлешер кешем юк менә. Ә хәзерге хатын-кызларның күбесе малга хирыс бит. Аларга мин үзем түгел, фатирым гына кирәк булуы бар, дип башка өйләнмәдем".

**Хатыйп ГӘРӘЙ**

***Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН:***

# "ИМАМНАР ДӨНЬЯВИ ҖӘМГЫЯТЬТӘ МӨНӘСӘБӘТЛӘРНЕ КОРА БЕЛЕРГӘ ТИЕШ"

***(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)***

бер, милләтебез - бер, Пәйгамбәребез - бер, Китабыбыз - бер, кыйблабыз - бер. Сөекле Пәйгамбәребез (с. г. в.) үзенең бер хәдисендә: "Гыйлем алу, гыйлем тарату - һәрбер мөселман өчен фарыз эштер", - ди. Әйдәгез, Аллаһ барыбыздан разый булсын, ниятләребезне кабул итсен", - диде мөфти хәзрәтләре.

ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары - Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департамент җитәкчесе Александр Терентьев билгеләп үткәнчә, республикада элек-электән ислам белән бәйле белем бирүгә, квалификацияне күтәрүгә зур игътибар бирелә. "Дини оешмаларның инициативасы РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкиллегендә хуплау табу шатландыра", - диде А.Терентьев.

Татарстан Республикасы буенча Баш федераль инспектор Ренат Тимерҗанов та Ислам дин әһелләренең квалификациясен күтәрү үзәген ачу идеясенең РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабичта хуплау табуын әйтеп китте. Республикада инде ике ел дәвамында Россия ислам институты нигезендә имамнар өчен курслар оештырылып килүен, анда тупланган тәҗрибәнең бүген эшли башлаган үзәк эшчәнлегендә файдаланылачагын хәбәр итте.

"Бүген хәлләр гадәти түгел. Шул исәптән, дини өлкәдә дә. Теге яки бу мәсьәләгә карата төрлечә караш белдерү, төрле агымнар бар, дини әдәбият та төрле - кайсын файдаланырга кирәклеген болай гына төшенеп бетеп булмый. Нәкъ менә шушы курслар безгә - традицион исламны тотучыларга - шушы әйберләрне дөрес аңларга һәм кирәкмәгәннән котылырга, дошман идеологиясен алып килүчеләргә һәм йортларыбызда фетнә тудыручыларга киртә куярга ярдәм итәрдер, мөгаен", - диде ул.

Мондый үзәк тиздән Россия ислам институты базасында Уфада да эшли башлаячак.

***Римма ГАТИНА, "Татар-информ"***

# ҺӘРКАЙСЫБЫЗ ЯРДӘМ КУЛЫ СУЗСА...

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Анжела Вавилова исемендәге хәйрия фонды белән берлектә ДРКБның онкогематология бүлегендә дәваланучы балалар өчен "Чиксез шатлык" исемле акция үткәрде. Әлеге чара шаян клоуннар чыгышы белән башланып, атаклы музыкант Ринат Вәлиев һәм җырчы Илгиз Шәйхразиев чыгышы белән дәвам итте. Акциянең максаты - балалар онкологиясе проблемасына киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итү, дәвалану курсы озучы балаларның бераз булса да кәефләрен күтәрү. "Без кеше кайгысы турында бик уйламаска тырышабыз, ә бит күпме баланың бәләкәй иңнәренә шушындый авыр сынау төшкән. Һәркайсыбыз ярдәм кулыбызны сузса, алар да хыялларының тормышка ашуына өметләнә алыр иде", - ди Диния нәзарәтенең хәйрия һәм социаль ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Ләйсән Дәүләтшина.

Концерттан соң балаларны корбан итеннән әзерләнгән пылау һәм бүләкләр көтә иде.



# ИРЕКСЕЗДӘН АСТРОНОМ

***(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)***

лап, кояш батканчы ашамый, эчми вә якынлык кылмый тору..." Әгәр таң аткач сәхәр дип ашап утырабыз икән, бу уразаның кабул булуы зур шик астында! Шуңа күрә элекке календарьларда август башында сәхәрне тәмамлау белән кояш чыгу вакыты арасы 3 сәгать тәшкил итә. Һәрхәлдә, Каюм Насыйри календаренда шулай. Гадәттә, астрономнар санавы буенча, таң вакыты кояшның офык астындагы почмак 18 градуска туры килгәндә башлана. Моны борынгы ислам астрономнары да шулай санаган. Мәсәлән, 929 нчы елда вафат булган әл-Бәттәни дә, 1048 нче елда үлгән Бируни һәм башка астрономнар да шул фикердә торган.

Үткән елларда рамазан айлары кыш, көз көннәренә туры килгәч, бу проблема бик сизелмәде, нәфел уразасы тотучылар аны үзләре хәл иткәндер, ләкин рамазан җәй уртасына таба бара, ничәдә сәхәр тәмам булганын төгәл билгеләргә кирәк.

Шулай итеп, инде 25 елга якын без намазларыбыз вакытына игътибарсызлык күрсәтеп килдек. Белүемчә, мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб кына бу эшне игътибар үзәгенә алды, мәсьәләне махсус өйрәнеп, аерым календарь төзегән иде. Аның бу изге эшенең дәвамчылары табылсын иде дигән теләктә калам, чөнки ирексездән астроном булып, "гражданские, астрономические, навигационные сумерки", "зодиакальный свет", "долгота-широта"ларны өйрәнергә һәркем булдыра алмый.

**Фатыйх ХӘБИБ**

# Игелекле эшкә кушыласызмы?

**Казандагы Тернәкләндерү үзәген һәм мәчетне үз эченә алган "Ярдәм" комплексы Россиядә әлегә бердәнбер.**

Әлеге комплекс сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен уникаль укыту-тернәкләндерү курсларыннан гыйбарәт. Рухый тернәкләнү һәм сихәтләнү өчен бирегә мөселманнар Россиянең төрле төбәкләреннән килә. Алар өч тапкыр бушлай туклану, тору урыны белән тәэмин ителә. Моннан тыш без юл чыгымнарын да үз өстебезгә алабыз.

Тернәкләндерү процессы махсус җиһазландырылган бүлмәләрдә бара. Сукырлар өчен көйләнгән компьютер классы, йорт эшләренә өйрәнү бүлмәсе, релаксация, массаж бүлмәсе бар.

Бездә ДЦП диагнозлы авырулар да тернәкләнү курслары уза. Алар белән махсус җиһазландырылган футбол мәйданчыгында әзерлекле физкультура работниклары шөгыльләнә. Болардан тыш ислам нигезләрен өйрәнергә теләүчеләр өчен, Коръәнне ятлау курслары, "Яшь мөслимә" һәм "Эшлекле хатын-кызлар клубы" эшли. Шулай ук Луи Брайль системасы буенча китап бастыру типографиясе, сукырларга аудиокитаплар әзерләр өчен тавыш яздыру студиябез дә бар. Киләчәктә күнегүләр өчен җайланмалар да алырга җыенабыз.

Бу эшләр иганәчеләр (меценатлар) ярдәме белән алып барыла. Сез дә шушы игелекле эшкә кушылып, үз өлешегезне кертерсез, дигән өмет белән "Ярдәм" илкүләм мөселман хәйрия фондының реквизитларын тәкъдим итәбез.

*НИБФ "Ярдэм" ИНН 1658087725 КПП 165801001 БИК 049205815 ОГРН 1071600003530 р/с 40703810800000000289 к/с 30101810100000000815 в ОАО АИКБ "Татфондбанк" г. Казань. Назначение платежа: "Благотворительная помощь на деятельность фонда".*

**Акчаны шулай ук QIWI терминаллары аша да күчерергә мөмкин**

# ТУЗМЫЙ ТОРГАН БҮЛӘК




***Замандашыбыз Сәйдә абыстай Аппакова - гасыр белән гасыр кисешкән дәвердә Казан мәктәпләрендә диннәр тарихын, гарәп телен укытуны башлап җибәргән мөгаллимә, бүгенге шартларда мәктәпләрдә дин сабаклары бирүнең уку-укыту программасын, методикасын булдырган мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, танылган вәгазьче, дәгъвәт остасы.***

Күптән түгел "Акчарлак" нәшрият йортында аның "Тузмый торган бүләк" дигән китабы басылып чыкты. Китапның төзүчесе, мөхәррире - журналист Вәсилә Рәхимова. Аны халыкка тәкъдим итү кичәсе Габдулла Тукайның Казандагы музеенда узды. Кичәдә динебез әһелләре, галимнәр, журналистлар, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләре катнашты.

## *Россия ислам институты юбилеен каршылый*

Россия ислам институты быел үзенең ***15 ЕЛЛЫК*** юбилеен билгеләп үтә. Октябрь азагында әлеге датага багышланган бәйрәм чаралары көтелә. Бәйрәмнең тантаналы өлеше ***28 нче октябрьдә РИИ бинасында (Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт)*** була. Ә **29 нчы октябрьдә** КФУның УНИКС мәдәни-спорт комплексының кече залында "Мөселман уку йортларында укыту процессын камилләштерүдә инновацион технологияләр" дип исемләнгән чираттагы халыкара фәнни-гамәли конференция була. Анда Россия, Урта Азия һәм гарәп илләреннән күренекле галимнәр һәм ислам тәгълиматчылары катнаша. Конференция аерым секцияләрдә эшен дәвам иттереп, Болгарга экскурсия белән тәмамланачак.

## *Болгарга укырга килегез!*

Казандагы Болгар мәчетендә якшәмбе курслары эшли башлый. Ислам нигезләрен укыту рус телендә алып барылачак. Укулар **шимбә көннәрендә көндезге сәгать икенче яртыда (13.30) башлана**. Өстәмә мәгълүматны *89172509153* телефонына шалтыратып белә аласыз.

## Урта Пошалым мәчетен бергәләп төзик!

Хөрмәтле авылдашлар, якташлар, милләттәшләр һәм дин кардәшләр! Аллаһы Тәгалә кушып, Татарстан Республикасының Арча районы Урта Пошалым авылында мәчет төзелә. Халыкта, ил төкерсә, күл була, диләр. Әйдәгез, шушы саваплы эшне бергәләп башкарыйк! Күгебездә тагын бер изге ай калыксын!

Изге гамәлдә матди ярдәм кылырга теләүчеләр өчен, мәхәлләнең Россия Саклык банкындагы исәп-хисап счёты номеры: 42307810262165010034/ 48.

**Корр. счёты номеры: 20202810167000100679.**

Шулай ук, мәчет төзелешенә акчалата ярдәмне авылда (имам-хатыйбка яисә мәхәллә казначеена) калдырып китәргә дә була.

**Элемтә өчен телефон: 89178689729 (Рәшит Галләм).**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №14 (209) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35423.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 24 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**